БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» 07 2022 ел № 220

«Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты хезмәткәрләренең эш сәфәренә (командировкаларына) бәйле командировка чыгымнарын каплау тәртибе һәм күләмнәре турында» 2019 елның 30 декабрендәге 402 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 168 статьясы нигезендә, бюджет акчаларын нәтиҗәле файдалану, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты хезмәткәрләренә җирле бюджеттан финанслана торган командировка чыгымнарына бәйле чыгымнарны түләүне тәртипкә салу һәм «Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен эш сәфәренә (командировкага) җибәрү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 7 июнендәге 133 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты хезмәткәрләренең эш сәфәренә (командировкаларына) бәйле командировка чыгымнарын каплау тәртибе һәм күләмнәре турында» 2019 елның 30 декабрендәге 402 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты хезмәткәрләренең эш сәфәренә (командировкаларына) бәйле командировка чыгымнарын каплау тәртибе һәм күләмнәре турында нигезләмәнең 4 пунктындагы б) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Даими яшәү урыннарыннан читтә яшәүгә бәйле өстәмә чыгымнар (тәүлеклек акча) муниципаль хезмәткәргә, ял һәм бәйрәм көннәрен, шулай ук юлда булган көннәрне, шул исәптән юлдагы тукталыш вакытын да кертеп, эш сәфәрендә булган һәр көн өчен түләнелә, Татарстан Республикасы территориясендә эш сәфәрендә булган һәр көн өчен 400 сум күләмендә, Татарстан Республикасыннан читтә – 400 сум күләмендә, федераль әһәмияттәге Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Севастополь шәһәрләренә эш сәфәренә җибәрелгәндә 700 сум күләмендә түләнә»;

2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгына Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты хезмәткәрләренең командировка чыгымнарын каплаганда әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән нигезләмәгә һәм гамәлдәге законнарга таянып эш итәргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет-ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов